СОВЕТ
МАТАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАТАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422473, Россия, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с. Матаки, ул. Колхозная, д.2
тел. (84375) 38-1-18, 38-1-17 факс. 38-1-18 E-Mail: Matak.Drz@tatar.ru
ИНН 1617003243

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 ноябрь 2020ел №3/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында " 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Матак авыл җирлеге Уставы нигезендә

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Советының 2020 елның 26 февралендәге 52/1 номерлы карары(02.06.2020ел, № 57/2 редакциясендә) белән расланган Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**11 статьяның 5 пунктын** түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.».

**15 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасына** түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән затта Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмаганда башкарыла.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән

көннән соң 90 көн эчендә җайга салынганда, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү шундый билгеләнеш сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карар, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпреле муниципаль районы
Матак авыл жирлеге башлыгы: В.П.Мердеев